


7-8 февральдә туган тел белvчеләре, яратучылары Казан шәһәренә жыелды. 17 тобәктән 110 бала белемнәрен сынап, татар теле һәм әдәбиятыннан Тобәкара олимпиадасында катнаштылар.

Мордовиядан оч 9 класс укучысы татар теленнән - Максутова Алина (Кырви урта мәктәбе), Сюбаева Алсу (Пензятка урта мәктәбе), Мангутова Земфира (Большие Поляны топ мәктәбе); 10 класс укучысы Старкова Рената (Тат. Юнки топ мәктәбе) һәм бишәv әдәбияттан - 9 класс укучысы Ямбушева Эльнара (Кырви урта мәктәбе), 10 класс укучылары Кадеева Регина (Алтар урта мәктәбе), Симаева Диана (Латыш урта мәктәбе) һәм 11класс укучылары Абузярова Айлина (Аксен урта мәктәбе) һәм Качкова Алена (Пензятка урта мәктәбе) кочләрен сынап карадылар. Безнен укучылар һәммәсе призерлар булып чыкты. Ботенебез шатландык, кәефләр кvтәрелде һәм бер-беребезне тәбрикләдек.      Разил Вәлиевнын һәм Фәнис Яруллиннын ижатына карата ижади конкурс 8нче февральда vтте. Мордовия укучыларынын барысы да яттан ойрәнгән шигырьләрен сәнгатьле итеп укыдылар, һәммәсенә беренче урын бирергә була иде. Татар теле һәм әдәбияты укытучыларына, балаларны тырышып укытканнары, ана телендә белем биргән очен, зур рәхмәт әйтәсем килә. Әмма Кырви мәктәбенен 9нчы класс укучысы Ямбушева Эльнара гына беренче  урын яулады.

Укучыларны Мәгариф министры  Э.Н.Фәттахов vзе котлады. Укучыларнын татар телен югары дәрәжәдә белvләрен хуплады. «Туган телне яратыгыз, туган телдә сойләшегез, киләчәктә ана телен балаларыгызга ойрәтегез! Шулай гына бергәләшеп, туган телебезне саклый алырбыз», - диде министр. Апрель аенда татар теле буенча булачак Халыкара олимпиадасына жинvчеләрне һәм призерларны чакырды.



Без Казанга 5 нче февральда килдек. Олимпиадага килvчеләрдән беренчеләрдән

булдык. «Регина» дигән гостиницанын бvлмәләренә урнашкач, Казан буйлап сәяхәткә чыктык. Башта Бауман урамында йордек, аннары Кремльга юнәлдек. Кремль каршындагы Муса Жәлилнен һәйкәле яныннан туктамый узып булмый. Боек шагыйрьнен батырлыгы турында, туган иленә, халкына тугрылыклы булуына баш иясен. Кремль эчендәге Кол Шәриф мәчетенен матурлыгына хәйран калып басып сокланып тордык. Мәчет эчендә Коръәннен сvраларын тынладык. Кибеттән торле китаплар, сувенирлар алып чыктык.Ерактан ук аз гына бер ягына авышканы кvренеп торган Соембикә манарасы янына бардык. Легенданы искә тошердек. Истәлеккә фотога тоштек.
7нче февральдә татар шагыйрьләре белән очрашу оештырылды. Разил Вәлиев, Рvзәл Мохәммәтшин, Йолдыз Шәрәпова vзләренен шигырләрен матур иттереп укыдылар. Безнен укучылар да Разил  Вәлиевнен шигырләрен сойләделәр.8нче февральдә Кәрим Тинчуриннын театрында “Киявләр” дигән комедияне рәхәтләнеп колеп карадык. Укучыларыбызга бик ошады.  Кайбер укучыларыбыз Казанда беренче мәртәбә булды. Алла бирсә, бергәләп апрель аенда да Казанга татар теле һәм әдәбияты буенча Халыкара олимпиадасына барачакбыз..
 Пензятка урта мәктәбе укучыларынын әниләре Качкова Лариса Харисовна һәм Сюбаева Альмира Рәстәмовна материаль ярдәм кvрсәткән спонсорларга Пензятка авылынын мәчете, Үзәк собор мәчете, “Ускудар” мәчете, Фагим –хазрәт Шафиевка рәхмәтләрен белдерәләр.

**Рауза Юмаева**